РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.03.2020 № 375-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 9 июнендәге 586-п номерлы карары белән расланган әйләнештәге акчаларны тулыландыруга һәм (яки) инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (заемнар) буенча процент ставкаларын каплауга җирле бюджет акчалары хисабына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең “Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - эшләр, хезмәт күрсәтүләр, товарлар җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Әйләнештәге акчаларны тулыландыруга һәм (яки) инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (заемнар) буенча процент ставкаларын каплауга җирле бюджет акчалары хисабына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2017 елның 9 июнендәге 586-п номерлы карары белән расланган әйләнештәге акчаларны тулыландыруга һәм (яки) инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар (заемнар) буенча процент ставкаларын каплауга җирле бюджет акчалары хисабына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.7 пунктының бишенче абзацында “банкротлык” сүзен “аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов